Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.07.2020 Менделеевск ш. № 263

Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтүләр җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибе хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставы

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ**:**

1. Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарәсенең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр әлеге белешмәләрне

бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чараларын күрү тәртибен расларга (Кушымта).

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга, шулай ук Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен, кеше хокукларын һәм депутат этикасын үтәү буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет Рәисе В.С.Чершинцев